УДК 908

***Симон Соргенфрей,***
***Ялкын Янбаева-Әхмәтгалиева,***
***Илида Бәширова***

# ШВЕЦИЯДӘГЕ БЕРЕНЧЕ ТАТАР МӨСЕЛМАННАРЫ

Статья посвящена первой группе татар в Швеции, заложивших основы первому в стране мусульманскому обществу и организации под названием Шведская Тюркско-исламская ассоциация по религии и культуре (The Turk-Islam Association for Religion and Culture in Sweden). В статье представлены самые важные персоны этой организации, а также даны некоторые особенности организации и её деятельности.

**Ключевые слова:** Швеция, группа татар, Тюркско-исламская ассоциация, важные персоны организации

The article is devoted to the first group of Tatars in Sweden, who laid the foundations for the country's first Muslim society and organization called The Turk-Islam Association for Religion and Culture in Sweden. The article presents the most important people of this organization, and also gives some features of the organization and its activities.

**Key words:** Sweden, group of Tatars, Turkic-Islamic Association, important people of the organization.

## Швециядәге беренче мөселман кешесе

Швециядә төпләнгән беренче мөселман кешесе дип Ибраһим Гомәркәевне (Умиркаефны) (1877–1954) санарга мөмкин. Ул Стокгольмга Россиянең Пенза төбәгеннән чама белән 1897–1898 елларда килгән булырга тиеш. Төгәл датаны атавы кыен, чөнки 1860–1917 елларда Швециянең чикләре ачык булган. Шуңа күрә әлеге вакыт аралыгында Швециягә килгән яисә аннан киткән кешеләрнең санын төгәл билгеләп булмый. 1906 елда Россиядә сәяси тотрыксызлык башлангач, аннан килгән мигрантлар контрольгә алына, 1914 елдан Европага чыгучы һәр кешедән паспорт таләп ителә башлый.

И. Гомәркәевкә мөнәсәбәтле беренче рәсми документлар ул Швеция гражданлыгы алган 1919 елдан теркәлгән. И. Гомәркәев Стокгольмга Россия мехчылар делегациясе составында 1897 елның 15 маеннан 3 октябренә кадәр Дьюгартен шәһәрендә үткәрелгән Сәнәгать күргәзмәсенә килгән. Ул биредә үзенең булачак хатыны Мария Элизабет Хулт белән танышкан, дип тә сөйлиләр. Мария дә мехчылык һәм тукыма җитештерү тармагында эшләгән. Әмма бу мәгълүмат архивтан бирелгән рәсми информациягә туры килми. Ибраһим Гомәркәев 1919 елда Швеция гражданлыгы ала. Шуны рәсмиләштергәндә полиция бүлегендә сөйләгән сүзләренә караганда, ул 1877 елның 15 октябрендә крестьян гаиләсендә туган, әтисе –

Латыйф, әнисе Камилә Гомәркәевләр булган. Ул туган авылда җиде яшьтән унике яшькә кадәрге барлык балалар да мөселман мәктәбендә укыган. Ибраһим 16 яшькә кадәр үзенең гаиләсе белән яши, күпмедер вакыт этисе хуҗалыгында эшли. Абыйсы Гафур Гомәркәев белән мехчы һөнәрен үзләштерә, берничә мәртәбә Финляндиядә була. 1898 елда хәрби хезмәткә алына, ләкин йөрәк авыруы булу сәбәпле, тиздән аннан азат ителә. Моны раслаучы документлар гаилә архивында саклана.

Полициядә сөйләгәннәреннән аңлашылганча, Стокгольмга ул 1898 елның 25 декабрендә, ягъни Дьюгартен күргәзмәсеннән соң бер ел вакыт узгач килә. Швециядә төпләнеп яши башлаганчы, Даниядә һәм Норвегиядә булып кайта. Башта «Сегерборг» дип исемләнгән фирмада йомышчы малай булып эшли, аннан соң хатыны Мария Элизабет Хултның мехчылык берләшмәсендә идарәче вазифасын башкара. 1906 елда үзенең бизнесын башларга рөхсәт ала һәм Рус мехы кибетен ача. Рәсми архив документларыннан күренгәнчә, ул Мария Элизабет Хултка 1900 елда өйләнә, бер елдан соң аларның уллары Хөсәен туа. Гаилә архивы материалларына караганда, Ибраһим һәм Мария 1919 елның 27 декабрендә өйләнешкәннәр, никахлары Хедвиг Элеонора чиркәвендә теркәлгән. 1918 елгы документ буенча, Мария бу вакытта әле Россия гражданкасы булган, димәк, алар 1900 елда Россиядә өйләнешкән булырга да мөмкин. 1919 елда, Ибраһим Швеция гражданлыгы алганда, аларның никахы икенче мәртәбә рәсмиләштерелә. Бу турыда Ибраһимның гаризасында да әйтелә.

1927 елда алар аерылыша, 1929 елда Ибраһим үзенең кибетендә эшләүче яшь кызга өйләнә. Бу хәл Ибраһимның улы Хөсәен һәм хәтта оныклары белән мөнәсәбәте катлаулануга сәбәп була. Оныгы Вера Тунмар сөйләвенчә, ул, әбисеннән яшеренеп кенә, бабасы белән очрашуын хәтерли, Мария Ибраһимны гафу итми (интервью, 2017 елның 2 ноябре). 1928 елда И. Гомәркәев банкротлыкка чыга, кибете ябыла. Аның банкротлыгы турында газетада игълан басылып чыга. Бу хәлгә Мария сәбәпче булса кирәк. И. Гомәркәев 1930 елда икенче мәртәбә өйләнгәннән соң, Биргер Ярлсгатан урамындагы 38 нче йортта яңа кибет ача. Бу – Стокгольм татарлары өчен генә түгел, Швециядәге барлык мөселманлар өчен дә мөһим адреска әйләнә.

Гомәркәевләрнең гаиләсендә сөйләнгәннәрдән, шулай ук архивларда сакланган документлардан, фоторәсемнәрдән аңлашылганча, 1930–1940 елларда И. Гомәркәевнең тормышы, эшләре гөрләп алга бара. Ул Стокгольмнан төньяктарак урнашкан Виггбихолмда дача ала. Бер фоторәсемдә без аны яшь хатыны һәм дуслары белән бергә моторлы көймәдә күрәбез. Кызганычка каршы, картлыгында ул ялгыз кала. 1954 елда ашказанындагы яман шеш авыруыннан вафат була. Аның мәетен кәфенгә төреп, цинк гробка куеп Финляндиягә алып китәләр. И. Гомәркәев Хельсинкидәге Садудде (финчә Хиетаниеми) татар зиратында җирләнгән.

**Швециядә татар җәмгыяте оешу**

Олыгыя башлагач, И. Гомәркәев Стокгольмда яшәүче татарлар белән якыннан аралаша башлый. Ул аларның күбесенә шәһәргә килеп яши башлаганда ярдәм иткән була. Икенче бөтендөнья сугышының ахырына таба Балтыйк буе илләреннән Финляндиягә күченүче татарларның саны шактый күп була. Аларның кайберләре СССРга каршы сугышкан Фин армиясенә кушыла. Кайберләре, Советлар Союзына кайтырга куркып, Швециягә кача. Швециягә беренчеләрдән булып килүчеләрдән Али һәм Зәйнәб Закировлар (яңа туган кызлары Дидар белән) гаиләсен атарга мөмкин. Алар Эстониянең Таллин шәһәреннән күченгән татарлар була (Дидар Самалетдин белән интервью, 2017 елның 6 декабре). Али Закиров Эстониядән немец армиясенә мобилизацияләнүдән куркып китә. Таллинда аның бөтен байлыгы конфискацияләнә, гаиләсе бөлгенлеккә төшә. 1943 елда Али Закиров авырлы хатыны белән бергә Финляндиягә юл тота, Дидар шунда туа. Бер ел дигәндә, бу гаилә турында хакимияткә җиткерәләр. Торнеадан төньяктарак, Ала-Вояккалада, Финляндия белән Швеция чигендә, Закировлар, контрабандистларга акча биреп, елганы кичәләр. Икенче ярда алар чик сакчылары кулына эләгә һәм Умеадагы качаклар лагерына озатыла.

Али Закиров Финляндиядә үк Ибраһим Гомәркәев турында ишеткән була. Аның белән очрашу өчен, Умеадан Стокгольмга И. Гомәркәевнең Мех кибете урнашкан Биргер Ярлсгатан урамына килә. И. Гомәркәев Виггбихолмда аңа үзенең дачасы янындагы бер коттеджга вакытлыча урнашырга ярдәм итә. Али Стокгольмда мехчы булып эшли башлый, гаиләсен дә үз янына алдыра (Дидар Самалетдин белән интервью, 2017 елның 6 декабре).

Башка татарлар да Финляндия чиген узып, Швециягә күченә. Вакытлыча качаклар лагерында булып, Швециянең төньягындагы урманнарда бераз эшләгәннән соң, алар да И. Гомәркәев янына киләләр, аның дачасында яшиләр, Стокгольмда эшкә урнашып, биредә төпләнеп калалар. Шулай итеп, Виггбихолмдагы дача Швециягә килүче беренче мөселман татарлар өчен транзит урыны булып хезмәт итә.

1944 елда, мәсәлән, Стокгольмга Түбән Новгородтан Вәлиулла Фәткуллин, Эстония гражданины төрек Ибраһим Зарип килә. Шул ук елны Истанбулда туган, Бакуда (Азәрбайҗанда) үскән, аннан соң Мәскәүдә яшәгән Йосыф Алиоглу күченә. В. Фәткуллин Стокгольмга килеп эшкә урнашканчы, Гевле һәм Оскелбо лагерьларында эшли. И. Зарипның Эскилстуан фермерындагы хезмәте тәмамлана. Й. Алиоглу, эшкә урнашканчы, Хапаранда, Людвик, Крилбо һәм Фагерста лагерьларында эшли.

1945 елда Хәйрулла Салихан килә. Чит ил эшләре буенча Дәүләт комиссиясенә белдерүенчә, ул Териокиядә (Финляндия) туган (хәзерге Зеленогорск, Россия), аның әти-әнисе – уллары туганчы, озак еллар Россиядә яшәгән төркиләрдән. Шул ук елны Рафат Сәлах килеп төпләнә. Ул Териокиядә (Финляндия) туган, Ленинградта яшәгән,

1934 елда кулга алынган, аннан соң гаиләсе белән Финляндиягә качкан. Алар икесе дә Катринехолмедагы Мех компаниясенә эшкә урнаша. Й. Алиоглу машина төзелеше заводында эшли башлый. Шушы ук елларда Швециягә Алибәк Вәлибәк тә килгән булырга тиеш, әмма Чит ил эшләре буенча Дәүләт комиссиясе архивында да, Миграция агентлыгы архивында да аның документлары табылмады. Тюркер Суккан истәлекләренә караганда, Вәлибәк Финляндиягә, бию ансамбле составында, сугышка кадәр үк килгән булырга мөмкин. Бу кешенең татарлар очраша торган кафесымы, кечкенә ресторанымы булган дип фараз кылына. Х. Самлихан, Т. Сукканның хатирәләрен дәвам итеп, Швециягә А. Вәлибәк белән бергә 1945 елда килдек, дип белдерә (интервью, 2019 елның 16 мае).

1947 елда Нарвадан (Эстония) Швециягә Әхмәд Хәертдинов, үзен төрки чыгышлы дип санаган СССР гражданины Хәлиулла Утарбай Финляндиягә күченә, соңрак Швециядән сәяси сыену хокукы сорый. 1948 елда Виллманстрандега (Липпеерантан) Финляндиядә «рус гаиләсендә» туган Мансур Насреддин килә.

«Төрки» дигәндә, күпчелек очракта «татар тамыры» күздә тотыла, ләкин кайчагында килүченең ата-аналары Төркиядән дә булырга мөмкин. «Татарин» диясе урында «турок-төрки» дип атауның берничә сәбәбен күрсәтеп була. «Таттаре» шведча – рус телендәге *варвар* кебек, кешене кимсетә торган сүз. Финляндиядә, Швециядә «төрек»кә тиңләштерү 1920 еллардан соң, Ататөрек җитәкчелегендә яңа республика ныгыгач активлаша. Татарларның күбесе үзләрен төрек дип атый. 1960 елларга кадәр, хәтта 1980 елларда да Финляндия татарлары үзләрен шималь (төньяк) төрекләре дип исемли [Стехлберг, 2012].

1940 елларда Швециягә килгән татар качакларының үзләрен төрек дип атап, төрек милләтеннән булырга теләүләренең стратегик сәбәбе дә яшеренергә мөмкин. Татарларның күбесен Түбән Новгородтан көньяктарак урнашкан Сергач районы татар-мишәрләре тәшкил итә [Соуккан, 1985]. XX гасыр башында аларның кайберләре Эстония һәм Финляндиягә юл тота. Сугыштан соң СССР җитәкчелеге кайбер этник төркемнәрнең илгә кайтуын таләп итә. Татарлар, туган илгә кайткан очракта, анда үзләрен каты җәза һәм үлем көтүеннән куркалар [Стехлберг, Сванбер, 2016, с. 202–203]. Үзләрен төрек чыгышлы дип белдергәннән соң, Швециядә калырга рөхсәт бирелмәсә дә, бәлки Советлар Союзына депортацияләнүдән котылып калып булыр, дип уйлыйлар. Мәсәлән, Йосыф Алиоглу һәм Рафат Салах Төркиягә куыла. Әмма Госманлы дәүләте аларга гражданлык бирми. Һәм алар Швециядә торып калалар, соңрак гражданлык алу мөмкинлеге дә туа.

Татарлар төркемендә Осман Соуккан исемле төрек тә була. Ул 1903 елда Госманлы империясе составындагы Македониянең Штип шәһәрендә туа. Османга 2–3 яшьләр булганда, әти-әнисе Измирга күченә. 27 яше тулгач, ул, дөнья күрәсе килеп, ике ел буена велосипедта Европа буйлап сәяхәт итә. Финляндиядәге Трасканда (финчә Ярвенпаа) шәһәренә килеп җиткәч, шундагы татар мәктәбенә

укытучы булып урнаша, тарих, төрек теле һәм ислам дине буенча дәресләр алып бара. Укучылар арасында Әминә Нисаметдин атлы бер чибәр кыз була (1920–2010). Кыз белән егет арасында гыйшык уты кабынып, 1939 елда алар өйләнешәләр. Әминә бер угыл, ике кыз таба. Гаиләсен матди яктан тәэмин итү өчен, Соукканга өстәмә эшләргә туры килә, ул төрле адреслар буенча товар таратып йөри (Тюркер Соуккан белән интервью, 2018 елның 7 феврале). 1948 елда алар Стокгольмга күченә, И. Гомәркәев аңа да үзенең дачасы янәшәсендәге бер коттеджга вакытлыча урнашырга ярдәм итә. Алар 1956 елда Швеция гражданлыгы алалар. Шул рәвешле, Швециягә килеп, тормыш башлап җибәргән татарларга Ибраһим Гомәркәев бик нык ярдәм итә: ул аларны вакытлыча үзенең дачасында тота, алар аның өендә, яки кибетендә эшли, билгеле бер вакыттан соң, шул илнең гражданнары да булып китәләр.

**Беренче мөселман оешмасы һәм ассоциациясе**

Али Закировның кызы Дидар Самалетдин сөйләвенә караганда (интервью, 2017 елның 6 декабре), 40 елларның уртасында яисә ахырында Швециягә килеп яши башлаган төрки-татарлар, гадәттә, шимбә көннәрдә, И. Гомәркәевнең Мех кибете янындагы Кйелсоннар кафесында очраша торган булалар. Алар – Швециядә беренче мөселман берләшмәсе булган Швед төрек-ислам җәмгыятен оештыручылар. Беренче җыелыш 1949 елның 27 октябрендә уза. Тюркер Соукканның шәхси архивында әлеге утырышның көн тәртибе күрсәтелгән язма сакланган. Шуның беренче пунктында болай диелгән: «Полиция хезмәткәре (констебль) Брор Хемпала Швеция хөкүмәтенең коммерцияле булмаган оешмалар өчен законнар чыгару мәсьәләсе турында кыскача гына белдерде. Әлеге законга нигезләнеп, «Швециядә яшәүче төркиләр тарафыннан, мөселманнар арасында ислам динен таратырга һәм мәдәниятне үстерергә ярдәм итү өчен, ассоциация оештырыла» дигән карар бертавыштан кабул ителде» (Оештыручылар документы). Җыелышның рәисе итеп Рафат Сәлах билгеләнә. Озак фикер алышулардан соң, тавыш бирү юлы белән, ассоциациягә «Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте оешмасы» (*«The Turk-Islam Association for Religion and Culture in Sweden»*) дигән исем бирелә. Вакытлыча җитәкчеләр итеп Рафат Сәлах, Ибраһим Зарип, Али Закиров, Әхмәд Хәердинов һәм Вәлиулла Фәткуллиннар сайлана.

«Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте оешмасы» җыелышының беренче беркетмәсендә, Осман Соукканның шәхси соравы буенча, аны берләшмәнең тулы хокуклы әгъзасы итү өчен, башта ярдәмче әгъза итеп кенә алу турында искәрмә бирелә. Тюркер Соукканның әйтүенә караганда, этисе, ассоциациянең тулы хокуклы әгъзасы булыр өчен, Швециядә ныклап төпләнү зарур дип санаган булса кирәк. Аның әле гаиләсе белән Төркиягә кайтып китү теләге дә көчле була. Әмма ул беренче көннәреннән үк оешманың имамы вазифасын башкара башлый (интервью, 2018 елның 7 феврале).

Икенче җыелыш 19 ноябрьдә була. Рафат Сәлах – ассоциациянең беренче сәркәтибе, Вәлиулла Фәткуллин рәисе итеп сайлана. Али Закиров – казначы, Ибраһим Зарип һәм Әхмәд Хәердинов аларның урынбасарлары итеп билгеләнә. Тагын өч кешегә: Вәлиулланың әтисе Хөсәен Фәткуллин, Хәйрулла Самлихан һәм Ибраһим Гомәркәевкә ревизорлык вазифасы йөкләнә (Тюркер Соуккан белән интервью, 2018 елның 7 феврале).

Җыелышының беренче беркетмәсендә үк Швециядә яшәүче мөселман татарларның үзләренә хас булган традицияләрне саклау, «төрки раса»дагы халыкка туклану өчен кирәкле азык-төлек булдыру әлеге оешманың төп максаты итеп күрсәтелә. Бу берләшмә, асылда, татар мәдәни җәмгыяте буларак, Швециядә яшәүче мөселманнарның дини гореф-гадәтләрен саклау белән шөгыльләнә. Беренче елларда төрле бәйрәм чаралары үткәрүгә аеруча зур игътибар ителә.

1950 елларда оешма зурая, Финляндиядән Швециягә яңа татар гаиләләре күченә, аларны да ассоциация эшчәнлегенә җәлеп итәләр. Тюркер Соуккан язганча, бу кешеләр барысы да мөселман булып, элек тә үзара белешеп, хәзер дә бер-берсенә ярдәм итешеп яшиләр: яңа килүчеләрне өйләрендә кабул итәләр, татар ризыклары әзерләп, мәҗлесләр үткәрәләр һ.б. [Соуккан, 1985, с. 108].

«Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте җәмгыяте»н оештыручыларның күбесе дөньяви белемле, мәдәниятле мөселман татарлары була [Мәдәниятле мөселманнар турында: Ларссон һәм Сандер, 2007, б. 153 – 154]. Алар исламның сөнниләр мәзһәбендә торып, ел саен үткәрелә торган дини бәйрәмнәрне оештыралар, яңа урында яшәргә җайлашканда, татар мәдәниятен, ана телен, язуын, милли ризыкларын югалтмыйча сакларга тырышалар.

## Җыелышмы яисә Ассоциацияме?

«Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте җәмгыяте»н җыелыш (собрание) дип түгел, Ассоциация (Берләшмә, ширкәт, ягъни сообщество, компания) дип исемләүнең юридик сәбәбе булган күрәсең. 1949 елдан Швециядә, дини закон буенча, Швеция гражданнарының барысы да Дәүләт чиркәвенә, яисә дәүләт тарафыннан расланган башка (мәсәлән, фрикиркор «ирекле» Ортодоксаль яки Католикбе чиркәве, Квакер, Еврей берләшмәләре, Христиан Фәне, яисә Свиденборгиан) чиркәүгә карарга тиеш булалар [Карлссон һәм Сванберг, 1997]. Ибраһим Гомәркәев, Швеция гражданлыгын алгач, әлеге юридик шартларга туры китереп, Остермале торгедагы Хедвиг Элеонора дине туганнарына карый торган Дәүләт чиркәвенең мөселман әгъзасы булып теркәлә. Мөселманнарның дәүләт тарафыннан расланган җәмгыяте (общинасы) булмаганга күрә, алар үзләрен ассоциация дип теркәүне таләп итә алган. 1873 елда кабул ителгән закон буенча, Швеция дәүләте тарафыннан расланган ислам дине союзы, димәк, мөселман оешмасы да булмый. Һәрхәлдә әлеге мәсьәләне җентекләп өйрәнәсе бар.

1951 елда Швециядә дин иреге турында закон кабул ителә, 1952 елдан ул гамәлгә куела. Шул елдан башлап, бу ил гражданнары үзләре теләгән теләсә нинди динне тотарга, яисә бернинди дин тотмаска хокуклы була. Шулай итеп, мөселманнар да рәсми рәвештә үз оешмаларын булдыру мөмкинлеге ала. Берничә елдан соң аларның оешмасы исемен үзгәртә һәм «Ислам собраниесе» *The Islam Congregation* дип атала башлый.

## Мөселманнар даирәсенең үсүе

1949 елның 22 октябрендә, «Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте җәмгыяте» союзы оештырылгач, мөселман зираты мәсьәләсен хәл итәргә кирәк була. 1950 елның 19 сентябрь беркетмәсендә теркәлгәнчә, Стокгольмның көньягындагы еврейлар каберлеге янында мөселманнарга да рәсми рәвештә җир бүлеп бирелә. Әлеге зират Швециядә мөселманнар даирәсен оештыруда бик әһәмиятле роль уйный. 1970 елларга кадәр үлгән кешеләр шушында җирләнә. Табигый ки, күченеп килгән кеше өчен аның ата-анасы, туганы, якыны күмелгән җир изге урынга әверелә.

Али Закировның кызы Дидар Самалетдин сөйләвенә караганда, Ассоциация Стокгольмда мәчет салу хәстәренә дә керешә. Али Закиров Швециянең премьер-министры Таго Эрландер белән очрашып, мәчет салуда ярдәм итүен сорый. Әмма бу эш премьер-министрга экзотика булып күренә. Ихтимал, ул төзеләчәк мәчетне Истанбулдагы «Зәңгәр мәчет» белән чагыштыргандыр, ди Дидар Самалетдин. Югыйсә татарлар кечкенә генә агач мәчет турында хыялланган була бит (интервью, 2017 елның 6 декабре).

Мәчетләре булмагач, татарлар кафеда очраша, яисә җомга намазларын Закировларның өендә үткәрә. Дидар хәтерләвенчә, әнисе Зәйнәб, өстәлләрне күчереп, намаз уку өчен, идәнгә келәмнәр җәя торган була. Соңрак, җыелышлар үткәрү яисә намаз уку өчен, Стокгольмдә Нормалмедәге Халык Йортында арендага бүлмә алуны гадәткә кертәләр. Ураза гаете, Корбан гаете кебек зуррак бәйрәмнәр өчен, Седермалмедагы Лиллиенхоф, яки Медборгархусет, яисә Хеторгетедәге Концерт залын арендага алалар. Кайбер елларда, Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көнен – Мәүлед бәйрәмен дә үткәрәләр.

## Мөселман татарлар журналы[1]

«Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте җәмгыяте» 1952 елда «Хәбәрче» дигән журнал бастырып чыгара. Журналда, нигездә, гарәп графикасы белән татар телендә языла, ягъни швед укучысыннан бигрәк, оешма кешеләре, шулай ук Финляндиядә һәм Эстониядәге татарлар өчен нәшер ителә. Журналның эчтәлеге дин-теология мәсьәләләреннән бигрәк, татар халкының тарихын яктыртуга багышлана, анда халык җырлары, Хуҗа Насретдин мәзәкләре туплап бирелә, Ататөрек

[1] «Хәбәрче» журналы турында тулырак мәгълүмат әлеге басманың «Фәнни ядкярләр» рубрикасында бирелә (б. 133–151).

турында поэма урнаштырыла, Стокгольмдә үткәрелгән ифтар турында искә төшерелә. Балалар өчен язмалар урнаштырыла. Тюркер Соукканның шәхси архивында бер журнал сакланган. Интернетта тагын шундый ук ике журналны табып карага мөмкин. Журнал бер генә мәртәбә басылган булса кирәк (инглиз теленә Я. Янбаева тәрҗемә итә). «Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте җәмгыяте»нең язма истәлеге югалу сәбәпле, Швециядә яшәүче татар-мөселманнарының эш-гамәлләре, уй-хыяллары, хәл-әхвәлләре турында безгә бик аз билгеле.

## Татарлардан интернациональ союзга

1950–1960 елларда Швециягә миграция көчәя, илдә мөселманнарның саны арта. 1970 елда аларның саны 9 меңгә җитә [Карлссон һәм Сванберг, 1995, б. 15]. Татарлар исә үзләре нигезләгән оешмада иң аз санлы булып кала. Башка этник чыгышлы кешеләр ислам динен үзләренчә саклыйлар. Алар татарларны читләштерәләр, үз итмиләр. Тюркер Соукканны, мәсәлән, 1960 елларда ук оешма эшенә катнаштырмыйлар. Оешма башка кешеләр хисабына киңәя (интервью, 2018 елның 2 феврале). Дидар Самалетдин да башта читләштерелә, ә 1990 елда Ассоциациядән бөтенләй китәргә мәҗбүр була (интервью, 2017 елның 6 декабре).

Ислам дине Ассоциациянең барлык әгъзаларын берләштереп тора. Мөселман татарлар өчен исә ислам яшәешнең әһәмиятле төп бер шартын тәшкил итә. «Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте җәмгыяте» (бигрәк тә башлангыч чорында) әлеге юнәлешне алып бара. Әмма вакытлар узу белән, бу нигез какшый, «татар тамыры» юкка чыга. Икенче һәм өченче буын татарларның күпчелеге әби-бабаларына тиңләшергә теләми, аларның телен һәм динен өйрәнергә кирәк тапмый, нәтиҗәдә, швед культурасы белән ассимиляцияләнә. Кайберләре, татар гаиләсендә үсеп, туган телен белгән очракта да, үзен татар дип санамый.

## Нәтиҗә

Архивларда системалы тикшеренү эше алып баруның нәтиҗәсе буларак язылган бу мәкаләдән аңлашылганча, «Төрки-ислам дине һәм мәдәнияте җәмгыяте»н һәм аның тарихын алга таба өйрәнгәндә, төп чыганакларны эзләп табарга тырышырга кирәк.

Швециядәге татар оешмасының тәүге әгъзалары булган кешеләрнең тормышын һәм эшчәнлеген тулырак аңлау максатыннан, аларның бүгенге көндәге нәсел дәвамчыларыннан мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат алырга тырышырга кирәк. Шул ук вакытта Россия, Эстония, Төркия архивларындагы материалларны барлау, аларны тирәнтен өйрәнү сорала.

Алга таба, Швециядәге беренче татар оешмасында торган кешеләрнең язмышын Финляндия, Эстония һәм Россия татарлары белән бәйләп тикшерү зарур. Швеция татарларының күбесе Финляндиядәге

татарлар белән тыгыз элемтә тоткан. Ибраһим Гомәркәев белән Осман Соуккан Стокгольмда татар-мөселман зиратын булдыру өчен күп көч куйганнар, әмма үзләре Финляндиядә җирләнгәннәр.

Швеция татарларының Эстония һәм Россиядәге татарлар белән бәйләнеше бөтенләй аз тикшерелгән. Россия архив материаллары Ибраһим Гомәркәевнең Швециягә килгәнгә кадәрге тормышына ачыклык кертер иде. Швециягә үзлегеннән килеп төпләнгән беренче татар һәм мөселман кешесе булганга, Ибраһим Гомәркәевнең язмышы зур кызыксыну уята.

Швед татарларының халыкара багланышларны үстерүдәге рольләрен дә анализлау сорала.

***Симон Соргенфрей,***
*Сёдертёрн Университеты (Стокгольм, Швеция)*

***Янбаева-Әхмәтгалиева Ялкын,***
*филология фәннәре кандидаты (Израиль)*

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре*